**СОВЕТ**
**АЛАН-БЕКСЕРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЛАН-БӘКСӘР**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru


**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**14 ноябрь 2024 ел** **№ 115**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябренда “Физик затларның мөлкәтенә салым турында” 7 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.10.2015 ел, №7 карарына (Советның 05.05.2018 ел, № 129, 20.09.2018 ел, № 143, 29.12.2018 ел, № 157, 29.11.2022 ел, № 67, 19.09.2023 №81, 13.11.2023 ел № 87 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата - 2,5 процент күләмендә»;

1.2. 2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына; Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата - 2025-2027 елларда 1,2 процент, 2028 елдан 2%».

2. Әлеге карар, рәсми рәвештә игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач, 2025 елның 1 гыйнварыннан законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина